**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«23» 10 2024 ел Яр Чаллы ш. № 111

16:39:021201:6203 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның «Кибетләр» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 16:39:021201:6203 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның «Кибетләр» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.
2. Халык тыңлауларын оештыручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле үзидарә турында, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә халык тыңлауларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
3. Халык тыңлауларын үткәрү 2024 елның 30 ноябреннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш, дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров

Республика Татарстан Муниципальное образование «Тукаевский муниципальный район» Совет Тукаевского муниципального района • ИНН 1639031685 • Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы • Тукай муниципаль берәмлеге